**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында гражданнар җыены карары**

15 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Тимбай авылында ял паркын төзекләндерүгә, кышкы чорда юлларны карап тотуга, җәйге вакытта территорияне чабуга (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тимбай авыл җирлеге башлыгы _________ И.Г.Айзатуллин

Гражданнар җыены секретаре _________ Г.А.Хакимова